**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 март № 128

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиалларында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче, 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче, 2015 ел, 27 июль, 545 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 1 790 646 сум күләмендәге айлык фонды белән 400 берәмлек итеп билгеләргә.».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең оештыру структурасын билгеләнгән тәртиптә билгеләгәннән соң ике ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче карарына, аны бу карар нигезләмәләренә туры китерү өлешендә үзгәрешләр

кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 27 июль, 545 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карарның көче 2016 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\128.docx